**Республика Татарстан**
**Шарлиареминское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районынын Шәрләрәмә авыл жирлеге**

---

**КАРАР**
**23.08.2024 ел**

**КАРАР**
**№15**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 24 декабрендәге «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 16 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гараж берләшмәләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 июлендәге 338-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 2 пункты, Сарман муниципаль районының «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл ажирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 24 декабрендәге «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 16 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаның 11 пунктына ", яисә физик затларның гомерлек мирас итеп биләгән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануында, әгәр мондый җир кишәрлеге әлеге Кодексны гамәлгә кертү көненә кадәр бирелгән булса һәм шул ук вакытта мондый җир кишәрлеге хосусый милектә була алмый икән“, сүзләрен өстәргә;

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда игълан итәргә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шәрләрәмә авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Н.Н.Хуҗина